| ГЛАВА ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.09.2022 с.Старое Дрожжаное № 31

Мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә судлар эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында» Федераль законның 10 статьясына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 14 июлендәге 270-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, КАКАР БИРЭМ: Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башлыгының 2013 елның 10 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган мәгълүматтан файдаланучыга аның соравы буенча Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**2.10 пунктының сигезенче абзацында** «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә» сүзләрен «рәсми сайтта» сүзләренә алмаштырырга;

**түбәндәге эчтәлекле 2.14** пунктын өстәргә:

«2.14. Җирле үзидарә органнарының һәм аның карамагындагы оешмаларның вазыйфаи затлары, муниципаль хезмәткәрләр, ведомство буйсынуындагы оешмаларның дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану хокукын бозуда гаепле хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, административ, гражданлык һәм җинаять җаваплылыгына тартыла.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

Чүпрәле муниципаль районы Башлыгы: М.Р. Гафаров